СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.09.2018 пос. Октябрьский 46-198

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 28-130 номерлы карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында,

Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау

турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 15 октябрендә 14.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрьский ав., Үзәк ур., 7 нче йорт адресы буенча уздырырга.

4. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерү һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советына карауга кертү.

5. 2018 елның 15 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов